ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БАВЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАУЛЫ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

18.09.2023 ел Баулы шәһәре №176

Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 4 ноябрендәге 232 номерлы “Баулы муниципаль районы муниципаль ихтыяҗларын тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәтләр сатып алуны гамәлгә ашыру буенча Бердәм комиссиянең Нигезләмәсен һәм составын раслау турында” карарына (2023 елның 10 апрелендәге 89 номерлы, 2023 елның 26 маендагы 122 номерлы үзгәрешләр белән) үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү.

2022 елның 11 июнендәге 160-ФЗ номерлы “Аерым төр юридик затлар тарафыннан товарлар, эшләр, хезмәтләр сатып алу турында” Федераль законның 3 статьясына үзгәрешләр кертү турында” һәм “Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәтләр сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында” Федераль законнары нигезендә Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР ИТӘ:

1.Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 4 ноябрендәге 232 номерлы “Баулы муниципаль районы муниципаль ихтыяҗларын тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәтләр сатып алуны гамәлгә ашыру буенча Бердәм комиссиянең Нигезләмәсен һәм составын раслау турында” (2023 елның 10 апрелендәге 89 номерлы, 2023 елның 26 маендагы 122 номерлы карарлары белән керткән үзгәрешләр белән) карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:

7.1. һәм 7.2. пунктларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7.1. Бердәм комиссия эше аның утырышларында башкарыла.

Бердәм комиссия әгъзалары комиссия утырышының уздыру урыны (кирәк чакта), датасы һәм вакыты турында вакытында хәбәрдар булырга тиеш. Комиссия әгъзалары дәүләт серен саклау турында Россия Федерациясе законнары таләпләрен үтәп, видео-

конференц-элемтә системаларын кулланып, мондый утырышта катнаша ала. Комиссия әгъзалары тарафыннан үз вәкаләтләрен башка кешеләргә тапшыру рөхсәт ителми.

7.2. Комиссия карарлары утырышта катнашучы әгъзалар санының гади күпчелек тавышы белән кабул ителә. Бердәм комиссия утырышы хокуклы дип санала, әгәрдә анда аның әгъзаларының ким дигәндә илле проценты булса. Тавышлар тигез булганда Рәис тавышы хәл иткеч булып тора.Тавыш биргәндә Бердәм комиссиянең һәр әгъзасының бер тавышы бар».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://www.pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы сайтында (http://www.bavly.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисади үсеш буенча урынбасарына йөкләтергә.

Баулы муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе Д.Л. Бакиров